*Октябрь, 2019*

# *Гимназия сулышы № 1*

***25- нче гимназия укучылары газетасы***







**Яңа уку елы белән!**

Быел Белем көне ялга туры килгәнгә, гимназиядә тантаналы линейка икенче сентябрьдә булды. Аллы-гөлле чәчәк бәйләмнәре тоткан, рәт-рәт булып тезелгән беренчеләр аеруча дулкынланалар, чөнки бу тантана алар өчен. Беренчеләрне котларга шәһәр профсоюзлар идарәсе рәисе Э.Р. Хәбибуллина , мәгариф идарәсе методисты Р.Р. Исмәгыйлева, Ак Барс банкы вәкиле Л. Юнысова, балаларның әти-әниләре килгән иде. Беренчеләргә матур теләкләр әйтелде. Беренче кыңгырау тавышы яңгырагач 182 укучы беренче дәрескә сыйныф бүлмәләренә юнәлде. Бәйрәм булгач бүләк тә була. Уналты беренче сыйныф укучысына микрорайон советы җитәкчесе М.П. Пичугина һәм гимназия директоры С.В. Гаранина уку әсбаплары бүләк иттеләр.

**Сайлаучылар өчен**

8 сентябрьдә Сайлаулар көнендә гимназия укучылары көче белән концерт оештырылды.



**Бөтен Россия тормыш иминлеге нигезләре дәресе**

3 октябрьдә гимназиянең спорт залында 8 сыйныф укучылары катнашында. Бөтенроссия тормыш иминлеге нигезләре дәресе үткәрелде.



Командалар «Беренче медицина ярдәме күрсәтү», «Ату», «Яшь янгын сүндерүче», «Туп ату», «Скакалда сикерү» этапларында үзләренең осталыкларын күрсәтте. Нәтиҗәдә, беренче урын иң яхшы результатлар буенча 8Д сыйныфына, икенче урын 8Б сыйныфына, ә өченче урын 8В сы йныфы командасына бирелде.

21 микрорайон сайлаучылары өчен «Аллегро», «Бию ритмнары» хореография коллективлары матур биюләр күрсәтте. Җырчы кызлар - Качаева Диана, Сивелькина Алинә, Әхмәдуллина Рания, Юлдашева Регина, Шәяхмәтова Даринаның дәртле җырлары сайлаучылар күңеленә хуш килде.

Вахапова Рената


Ә менә «Иң яхшы атучы» һәм «Яшь янгын сүндерүче» этапларында 8Д сыйныфы укучысы Сорокина Елизаветага тиңнәр булмады. Гимназиянең тормыш иминлеге нигезләре дәресләрен укытучы И.М. Мәрданшин әйтүенчә, ярышта катнашучы укучылар тормышта көтелмәгән - гадәттән тыш ситуацияләрдә югалып калмаслар , үзләрен генә түгел, якын кешеләрен дә саклап кала алырлар.

Хәйруллина Диләрә



**Татарча диктант яздык**

19 октябрьдә безнең гимназия дә «Татарча диктант» - Бөтендөнья татар теленнән грамоталылыкны тикшерү акциясенә кушылды . Диктант язарга укучылар, аларның әти-әниләре, әби-бабайлары, 21 микрорайонда яшәучеләр килгән иде. Диктант текстын татар теле һәм әдәбияты укытучылары Гыймранова З.М., Гайнетдинова И.И., Осипова Г.Т., Шарапова Н.Н. укыдылар. Акциядә барлыгы 70 якын кеше катнашты. Барлык катнашучыларга сертификат тапшырылачак.







Акция турында ишеткәч, мин бик теләп татар теленнән грамоталылык дәрәҗәсен тикшереп карарга булдым. Укытучыбыз Осипова Гөлчәчәк Талип кызы Р.Миңнуллинның «Мин кулыма китап алам» әсәреннән өзекне укыды. Диктанттагы сүзләр язылышы минем өчен авыр булмады. Ә менә өзектә уйланырга мәҗбүр итә торган фикерләр бар иде. Әйтергә кирәк, хәзерге заманча гаджетлар аркасында күбебез әдәби әсәрләрне интернеттан табып укырга күнектек. Китап – тиңсез хәзинә, дигән мәкальне онытмаска иде.

Хуҗҗәтов Гадел






Укытучы! Нинди олы мәгънәгә ия бу сүз! Укытучы ул баланы хәреф танырга, укырга, язарга өйрәтү белән чикләнмичә, аны олы тормышта үз урынын таба алырлык шәхес итеп үстерә. Күренекле язучыбыз Фәнис Яруллин юкка гына : «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» - дип әйтмәгән.Чыннан да, кирәк чакта безне яклаучы да, мактаучы да, киңәшче дә – укытучылар!

**Кадерле мөгаллимнәребез!**

Сезне узган һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелебездән котлыйбыз! Һәрвакыт укучыларыгызның ихтирамын һәм рәхмәтен тоеп эшләгез!

***Чор сулышын ачык тоемлаучы***
***Зыялы һәм затлы кеше Сез.***
***Сезгә карап сокланабыз һәрчак***
***Күңелләрдә туа горурлык.***
***Рәхмәт Сезгә, әле ярый Сез бар***
***Безгә үрнәк булып торырлык!***



## «Түбән Кама гүзәле» бәйгесе

**«Түбән Каманың татар яшьләре» инициативасы белән шәһәр күләмендә « Түбән Кама гүзәле» бәйгесе үткәрелде. Бәйгедә катнашучылар арасында безнең гимназиянең 11 сыйныф укучысы Якупова Гүзәл бар иде. Сайлап алу этабы «Ковёр» шәһәр яшьләр үзәгендә узды. Гүзәлгә берничә сорау белән мөрәҗәгать иттем.**
**_ Гүзәл , бәйге турында сөйлә әле.**

- Башта әзерлек эшләре булды. Ул - визитка, яки үз-үзең белән таныштыру. Мин җырларга яратам, шуңа күрә «Сандугач» җырын инструменталь ансамбль белән башкарырга булдым. Сыйныфташларым Матвей, Максим, Кирилл белән репетицияләр ясадык. Укытучым Осипова Гөлчәчәк Талип кызыбелән күренекле татар шәхесләре, халкыбызның тарихы, мәдәнияты, милли бәйрәмнәре, кием үзенчәлекләре турында белемемне тирәнәйтү өстендә эшләдем.

**- Катнашучыларга килсәк, алар күп идеме?**
**- Бәйгедә 18-30 яшьләр аралыгында утызга якын кыз катнашты. Араларында минем кебек мәктәп укучылары, студент кызлар, тәрбиячеләр, укытучылар, китапханәчеләр, хәтта өч бала әнисе - хуҗабикә да бар иде.**
**– Гүзәл, конкурста нинди хисләр кичердең?**

- Чыгыш ясаганчы дулкынлану көчле булды , аннары үземне кулга алдым. Сыйныфташларым Матвейга, Максимга һәм Кириллга рәхмәт , алар минем таянычым булды. Финалга уза алмадым, шулай да бәйге барышында онытылмас эмоцияләр кичердем, үз мөмкинлекләремне бәяләдем, рухи яктан кәнагатьлек хисе алдым.

**– Киләчәктә яңа бәйгеләрдә уңышлар, сиңа, Гүзәл.**
– Рәхмәт.
Әңгәмәне Бакирова Алия үткәрде.



**Волонтёр буласың килсә…**

*<u>Соңгы вакытта волонтёрлар хәрәкәте турында еш ишетәбез. Шәһәрдә узучы һәртөрле чараларда очратырга була аларны. Кемнәр соң алар волонтёрлар? Сорауга җавап алу өчен Түбән Кама волонтёрлары хәрәкәтенең актив әгъзасы 8 Д сыйныфы укучысы Бакирова Алиягә мөрәҗәгать иттем.</u>*




– «Волонтёр» - инглиз теленнән үз теләге белән ярдәм итүче, дип тәрҗемә ителә. Алар элекке тимурчыларны хәтерләтә. Берьяктан карасаң аларны социаль хезмәткәрләр белән дә тиңләп була, ләкин волонтёрларга хезмәт хакы түләмиләр.

**– Алия, син волонтёр буларак нинди чараларда катнаштың?**

Август ахырында «Шәһәр көне»ндә «Гаилә»паркында балалар өчен «Рәсем ясау осталары» мәйданчыгында эшләдем. 8 сентябрьдә «Ишегалды проекты» буенча сайлаучылар белән анкета тутыру эшендә катнаштым. 20 сентябрьдә « Эшкә – велосипедта» акциясендә катнашучыларга сувенирлар өләшүдә катнаштым. «Җиңүгә 75 ел» проекты буенча 25 нче гимназиядә, тагын өч мәктәптә 5-8 укучылары өчен сыйныф сәгатьләрендә Ленинград блокадасы турында доклад ясадым.




**–Алия, волонтёрлык хәрәкәте сиңа нәрсә бирә?**

- Волонтёр булу ул – үзенә күрә бер тормыш тәҗрибәсе туплау, яңа дуслар табу. Мин волонтёрлар хәрәкәтендә икенче ел. Әмма бу дөньядан чыгасы килми. Яхшы гамәлләр эшләү күңелгә рәхәтлек, канәгатьлек хисе китерә.

**– Алия, сиңа игелекле эшеңдә уңышлар телим.**


Садриева Эльмира

**Легендар шәхес**




***2019 елның 14 ноябрендә Түбән Кама «Нефтехим» акционерлар берләшмәсенең беренче генераль директоры Николай Василий улы Лемаевның туууына 90 ел билгеләп үтелә. Ул 1963-1983 елларда Түбән Кама нефть-химия комбинатын җитәкли, 1985-1990 елларда СССР ның химия һәм нефть эшкәртү тармагы министры булып эшли, Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исемгә лаек була.***

Түбән Кама нефть-химиясе комбинаты төзелешенә генераль директор булып килгәндә Николай Лемаевка 34 яшь була. 60 нчы елларда шундый ук комбинат Себердә дә төзелә башлый. Нәкъ шул чорда Түбән Камадагы төзелешкә ябылу куркынычы яный. Николай Лемаев берничә тапкыр



Мәскәүгә барып, төзелешнеңтукталмавын таләп итә

Министрлыктагы чиновниклар каршында аңа комбинатның киләчәктә СССР экономикасына зур файда китерәчәген исбатларга туры килә. Н. Лемаевның фаразы чынга аша. Егерменче гасырның 80 нче елларында Түбән Кама нефть-химия комбинаты СССР да гына түгел, Европада зур нефть- химия гиганты буларак дан казана. Николай Лемаев яңалыкка омтылучан җитәкче була, шул ук вакытта комбинатта хезмәт куркынычсызлыгы таләпләрен бозучыларга карата бик кырыс була. Комбинат белән егерме ел идарә итү чорында, нефть-химия өлкәсендә яңа технологияләр кертү буенча техник фәннәр докторы дәрәҗәсенә ирешә.



Н.Лемаевның эш графигы бик тыгыз була. Комбинатта идарә итү белән бергә, ул Мәскәүгә Үзәк Комитетка барып , кирәкле ишекләрне ачып керә, шул рәвешчә шәһәр төзелеше кызу темплар белән барсын өчен акча даулый. Комбинат эшчеләренең уңайлы фатирларда яшәвен, дәвалану өчен хастаханәләр булуын, ял итү өчен кинотеатр, концерт заллары булуын тели ул. Шулай итеп, Николай Лемаев комбинат эшчеләренең генә түгел республика халкының ихтирамын яулый, аны үз итеп «Легендар Лемаев» дип атыйлар. Бу урында кызыклы фактны әйтеп китәргә кирәк. Н.Лемаев директор итеп билгеләнгәндә завод штатында нибары 40 кеше булса, 1983 елда Түбән Кама нефть – химиясе штатында 28 мең кеше исәпләнә.






2001 нче елда шәһәр хакимияте һәм Түбән Кама «Нефтехим» акционерлар берләшмәсе җитәкчелеге тарафыннан шәһәр үзәгендә Лемаев скверы яңартылып төзекләндерелә һәм легендар шәхес Николай Василий улы Лемаевка һәйкәл ачыла( вафатыннан соң). Ә 2019 нчы елда Бигеш аэропортына Н.В.Лемаев исеме бирелә. Шул рәвешчә шәһәр халкы олы ихтирамга лаек җитәкченең исемен мәңгеләштерә.
Яркеев Илья

**Кадерле газета укучыларыбыз!**

Мавыктыргыч күңелле җәйге яллардан соң, яңа 2019-20 20 уку елында сезнең белән очрашуга чиксез шатбыз! «Гимназия сулышы» редакциясе әгъзалары сезгә яңа уку елында укуда гел «5» билгеләр алуыгызны, буш вакытыгызны файдалы уткәрүегезне телибез! Яңалыкларыгыз, тәкъдимнәрегз булса түбәндәге электрон адреска мөрәҗәгать итә аласыз.

**Редактор: Якупова Г.Проект җитәкчесе: ШараповаН,Н. Хөрмәтле укучылар, яңалыкларыгыз , тәкъдимнәрегез булса 3023001035@edu.tatar.ru электрон адресына җибәрә аласыз.**